**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

Ленин пр.,17йорт, Актаныш ав.,423740

Тел. (85552)3-44-22, факс (85552)3-44-14, E-mail:aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ № ________

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау программасынраслау турында

Татарстан Республикасында террорчылыкка каршы комиссиянең 2019 елның 06 маендагы ПР–109 номерлы һәм 2020 елның 28 мартындагы ПР-73 номерлы карарлары нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында 2021-2023 елларга терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау программасын (алга таба- программа), кушымта нигезендә расларга.
2. Программада каралган чараларны гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.
3. Актаныш муниципаль районының финанс-бюджет палатасына бюджет формалаштырганда программа чараларын тормышка ашыруга, программаны тормышка ашыру срокларын исәпкә алып, район бюджеты акчалары бүлеп бирүне күздә тотарга.
4. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау буенча муниципаль максатчан программаны раслау турында» 2017 елның 14 декабрендәге ПР-222 номерлы карарын үз көчен югалткан дип санарга (үзг.белән 08.02.2018 №ПР-12; 07.12.2019 №ПР-299).
5. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aktanysh.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми порталында түбәндәге адрес буенча:http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе И.И.Габдулхаев